ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_23_» ____11____ 2020г.** **№ 902**

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәсе системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен Ютазы муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар бирүне, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территорияләре чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә» раслау турында" 2020 ел, 9 октябрь, №777 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 ел, 9 октябрь, №777 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территорияләре чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәсе системасын

үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен Ютазы муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия алучыга субсидияләр алу өчен Башкарма комитетка тапшырырга кирәк:

- Җитәкченең фамилиясен, исемен, атасының исемен, субсидия алучының банк реквизитларын, элемтә өчен телефоннарын күрсәтеп, субсидия бирү турында язма гариза;

- Җирле үзидарә органы теркәгән Уставның нотариаль расланган күчермәсен;

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә шундый өземтәнең субсидия бирү турында гариза биргән көнгә кадәр бер айдан да элегрәк алынмаган (юридик зат буларак теркәлгән субсидия алучыга) нотариаль расланган күчермәсен;

- территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесен сайлау турында гражданнар җыелышының (конференцияләренең) беркетмәсен;

- Субсидия алучыда Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә түләнергә тиеш булган салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары юклыгы турында белешмә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә электрон челтәр массакүләм мәгълүмат чарасында http://yutazy.ru адресы буенча рәсми бастырып чыгару юлы белән (челтәр басмасы буларак теркәлү: № ФС 77 – 07.12.2011 ел, № 47613) урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет информацион-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

А. В. Сучкова
2-80-12